**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «06» сентябреннән № 36-298

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү һәм шулай ук «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 2014 елның 11 ноябрендәге 37-214 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-214 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 15 апрелендәге 43-262 номерлы, 2016 елның 20 апрелендәге 12-51, 2021 елның 02 июнендәге 10-74 номерлы, 2022 елның 30 маендагы 23-179 номерлы, 2022 елның 08 сентбрендәге 26-205 номерлы карарлары редакциясендә) «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү һәм шулай ук «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 16 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яки, белә торып хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында ялган белешмәләр бирү, әгәр мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, муниципаль хезмәткәрләрне алмаштырып торган (биләгән) вазифаларыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов